**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 03 » 10 2016 № 533

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 217 номерлы карары белән расланган объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (11 нче кушымта) үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 03 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының башкарма комитеты түбәндәгеләрне кертә:

1. “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 217 номерлы карары белән расланган объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (11 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.4.2 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
Әгәр ведомствоара мөрәҗәгатькә җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара мөрәҗәгать кергән көннән алып өч көн эчендә башкарыла.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Муратшинга йөкләргә.

Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Ф.Горбунов